ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Салым ташламалары инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектларына инвестиция проекты чыгымнарын каплау срогына, әмма инвестицияләр башлану вакытыннан алып җиде елдан да артык булмаган вакытка, әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, бирелергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Машина төзелеше тармагында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары инвестицияләр башлану вакытыннан алып 13 елга кадәр бирелергә мөмкин.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. Татарстан Республикасы территориясендә проект куәте елына кимендә 500 мең тонна этилен булган җитештерү куәтләрендә пиролиз ысулы белән этилен җитештерүне башкаручы, капиталь салулар күләме кимендә 10 миллиард сум

булган инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары җиде елга кадәр бирелергә мөмкин.».

**2 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21) Татарстан Республикасы территориясендә проект куәте елына кимендә 500 мең тонна этилен булган җитештерү куәтләрендә пиролиз ысулы белән этилен җитештерүне башкаручы, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәгә ярашлы рәвештә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмалар – яңа төзелгән яисә капиталь салулар күләме кимендә 10 миллиард сум булган инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында сатып алынган һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк файдалануга тапшырылмаган мөлкәткә карата.

Салым ташламасы, күрсәтелгән мөлкәт салым салу объекты буларак исәпкә алынган айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап, инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамәнең гамәлдә булу срогы беткәнче, әмма җиде елдан да артмаган срокка бирелә.

Оешма салым ташламасын салым чоры йомгаклары буенча түбәндәге шартларны үтәгәндә әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы:

бизнес-планда каралган шартлар үтәлү;

хисап елында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына оешмалар табышына салымның, физик затлар кеременә салымның, оешмалар мөлкәтенә салымның, транспорт салымының, җир салымының кушма суммалары һәм тиешле пенялар һәм штрафлар суммалары (салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларының һәм оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым өлешендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммаларының үзгәрешләре йогынтысын исәпкә алмыйча), хисап елына кадәрге өч ел өчен булып (йә, оешма төзелгән вакытны

исәпкә алып һәм әлеге пунктның җиденче абзацын исәпкә алып, хисап елына кадәрге башка чор өчен, ләкин ике елдан күбрәк түгел), тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткеченә, ул салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган форма буенча тапшырыла торган тиешле ел өчен икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре исәпләп бирелү һәм түләнү турындагы хисап белешмәләренә нигезләнеп билгеләнә, һәр ел йомгаклары буенча индексацияләнгән тиешле салымнарның (пеняларның, штрафларның) (салым ташламаларыннан файдалану өлешендә чагыштырма шартларда) оешма тарафыннан чынбарлыкта түләнгән суммаларының уртача арифметик күрсәткеченнән ким булмаган күләмдә түләнү;

Татарстан Республикасы финанс органына оешмага исәпләп бирелгән һәм аның тарафыннан түләнгән салымнар суммалары, салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммалары һәм артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммалары, бирелгән салым ташламаларының ташламалар киселешендәге суммалары турында белешмәләрне салым органы тарафыннан бирүгә ризалык бирелгән булу.

Яңа төзелгән оешма салым ташламасын салым буенча беренче салым чоры йомгаклары буенча, шушы пунктның бишенче абзацында билгеләнгән шартны үтәмичә, әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы.

Салым ташламасын әлеге пункт нигезендә куллануның шушы пунктның бишенче абзацында билгеләнгән шартының оешма тарафыннан үтәлүен бәяләү тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Мондый тәртиптә тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткечен исәпләп чыгару методикасы булырга тиеш.»;

2) $2^1$ өлешнең 2 пунктында «технопаркларның (индустриаль паркларның)» сүзләрен «технопаркларның, индустриаль паркларның (сәнәгать паркларының)» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 өлеше (әлеге Закон редакциясендә) һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты (әлеге Закон

редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 29 сентябрь
№ 89-ТРЗ